| | | |
|---|---|---|
| “Килешенгән”<br>МБ җитәкчесе:<br>_____Сафиуллина Р.Д.<br>Беркетмә№<br>“_7_”____ 2018ел | “Килешенгән”<br>Завуч:<br>_____Хайруллина Л.Ю.<br><br>“_7_”_____ 2018ел | “Раслыйм”<br>Директор:<br>_____Сафиуллин Х.С.<br>Боерык№ 187<br>“_7_”_____2018ел |

**Җәмгыять белеменнән белем бирү минимумы**

**Җәмгыять белемендә кабул ителгән терминнар һәм аларның кагыйдәләрен белергә.**
**8 класс**
**2 чирек**

| Терминнар | Кагыйдәләр |
|---|---|
| 1. Мәдәният | Җәмгыять әгъзасы буларак кеше үзләштергән белемнәрне, дини караш,ышануларны,сәнгать, әхлак, закон, гореф гадәтләрне,шулай ук сәләт һәм күнекмәләрне туплаган комплекс ул. |
| 2. Җәмгыятьнең рухи өлкәсенә керә | Тел, әхлак, дин, мәгариф, фән, сәнгать, философия, ягъни рухи культураның төрле рәвешләре һәм чагылышлары, шулай ук кешеләрнең иҗади эшчәнлеге керә торган өлкә. |
| 1. Әхлак /Мораль/ | Кешенең үз-үзен тотышын, аның башкаларга, әйләнә-тирә мохиткә һәм үз-үзенә мөнәсәбәтен яхшылык һәм явызлык,гаделлек һәм гаделсезлек ягыннан җайга салучы үзенчәлекле рухи кагыйдәләр. |
| 4.Жаваплылык /Ответственность | Аңлы рәвештә гамәл йөртү, кылганнарыңның башкаларга ничек йогынты ясаячагын аңлау, һәр адымыңның нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин булуын алдан ук күрергә сәләтле булу. |
| 5.Гуманлылык | Кешелеклелек, шәхеснең абруен, иреген һәм бәхеткә хокукын тану һәм шул ук вакытта аларны үтәү бурычы. |
| 6.Белем алу /Образование/ | Дөнья турында белемнәр туплау, мәдәният, Ватанның, дөнья цивилизациясенең рухи хәзинләре белән танышу процессы. |
| 7.Россиядә гомуми белем бирүнең баскычлары/Уровни общего образования в России/ | • Мәктәпкәчә белем бирү<br>• Башлангыч гомуми белем бирү (1-4 класс)<br>• Төп гомуми белем бирү (5-9 класс)<br>• Урта (тулы) гомуми белем бирү (10-11 класс) |
| 8. Фән/ Наука/ | Кешенең дөнья һәм кеше турында дөрес гыйлем алуга юнәлдерелгән рухи эшчәнлеге өлкәсе. |
| 9.Дин/Религия/ | Бер Алла яисә күп аллаларның, өстен көчләрнең барлыгына иненуга нигезләнгән дини күзаллаулар җыелмасы, һәм кешеләрнең шуларга корылган үз-үзен тоту рәвеше һәм үзенчәлекле гамәлләре. |
| 10. Вөҗдан ирege | Кешенең үз инануларын мөстәкыйль формалаштыруга һәм аларны башкаларның һәм җәмгыятьнең ирегенә зыян китермичә ачыктан-ачык белдерүгә хокукы. |